ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.10.2019 г. Заинск № 566

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында" Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 674нче (14.04.2017) карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"» 131нче (06.10.2003) Федераль законны, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"» 45нче (28.07.2004) Татарстан Республикасы законын, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында"» 14нче (07.03.2014) Татарстан Республикасы законын үтәү, муниципаль идарә процессларының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм җайга салу карарларын әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарә процессларын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында» 674нче (14.04.2017) карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары

проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1.2.1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2 1.2.6 пунктны «территорияләр, бирү» дигән сүзләрдән соң «җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, бирү» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2. Әлеге карар рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Карарның үтәлешенә күзәтчелек итүне башкарма комитет җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист
А.Н. Симашева
3 41 33